ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 апрель 2025 ел № 2466

Башкарма комитетның «Күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 19 сентябрендәге 4881 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 19 сентябрендәге 4881 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2023 елның 16 июнендәге 5184 номерлы, 2024 елның 16 февралендәге 1004 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 3755 номерлы, 2024 елның 25 октябрендәге 7077 номерлы, 2024 елның 5 декабрендәге 8132 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.»;

2) кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын, күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын (алга таба – проектлар) килештерү һәм имзалау муниципаль хезмәт  нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

- 4.1 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы Башкарма комитет Җитәкчесе, муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эш оештыруны гамәлгә ашыручы идарә башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

- 4.3 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең үз вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов